**СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2023 елның «06» сентябреннән № 36-290

2022 елда Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районында туфракның торышы һәм аны саклау, җир ресурсларыннан рациональ файдалану һәм 2023 елга бурычлар турында мәгълүмат

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Яңа Чишмә муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Л.Е. Богомоловның «2022 елда Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районында туфракның торышы һәм аны саклау, җир ресурсларыннан рациональ файдалану һәм 2023 елга бурычлар турында» мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елда Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районында туфракның торышы һәм аны саклау, җир ресурсларыннан рациональ файдалану һәм 2023 елга бурычлар турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Яңа Чишмә муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә тәкъдим итәргә:

- Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә хуҗалык итүче субъектларда барлык милек рәвешләрендәге җирләрнең уңдырышлылыгын саклау һәм арттыру буенча алга таба эш алып барырга;

- чәчүлек мәйданын седератлар белән арттыру өлешендә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрен тикшереп тору һәм мониторинглау эшен көчәйтергә;

- эшкәртелми торган җирләрнең санын киметү максатларында авыл хуҗалыгы формированиеләре үткәрә торган эрозиягә каршы чаралар буенча эшне көчәйтергә;

- эшкәртелми торган һәм куаклар белән капланган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең мәйданын киметү буенча эшне көчәйтергә.

3. Барлык милек рәвешләрендәге хуҗалык итүче субъектлар җитәкчеләренә минераль һәм органик ашламалар куллану эшен көчәйтергә, әче туфракны известьлау һәм туфракны төп эшкәртү технологиясен үтәү эшен активлаштырырга киңәш итәргә.

4. Авыл хуҗалыгы оешмалары җитәкчеләренә һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары башлыкларына чәчү әйләнешен, шул исәптән чиста парлар һәм беркетелгән авыл хуҗалыгы җирләрендә күпьеллык үләннәр чәчүне дәвам итүне тәкъдим итәргә.

5. Яңа Чишмә муниципаль районының Милек һәи җир мөнәсәбәтләре палатасына Россельхознадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән берлектә эшкәртелми яисә тиешенчә файдаланылмый торган авыл хуҗалыгы җирләре участокларына карата муниципаль контрольне көчәйтергә.

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының Экология, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм территорияләрне төзекләндерү буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы В.М. Козлов